**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Абляскино торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАР**

**25 ноябрь 2023 ел** **№ 7**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 25 ноябрендә узган: «2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге Абляскино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (мең сум) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

Торак пункт чикләрендә юлларны ремонтлау» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 100 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 60 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 49 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 11 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Абляскино торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга. 2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге Абляскино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (мең сум) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

Торак пункт чикләрендә юлларны ремонтлау

1. Су чыганакларын норматив таләпләргә китерү мәсьәләләре буенча кабул ителгән карарны танырга

2. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге Абляскино торак пункты мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: В.П. Вафина

Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы: В. П. Вафина